РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

*Решение* *Карар*

от 17 апреля 2019 года г.Чистополь № 43/6

Чистай муниципаль районы
Советының 2017 елның
4 октябрендәге «Татарстан Республикасы
«Чистай муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге милкендәге
мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү
тәртибе турындагы нигезләмәне
раслау хакында " 25/3 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә Чистай муниципаль районы Советы

Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының 2017 елның 4 октябрендәге №25/3 карары белән расланган “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы берәмлеге милкендәге мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турында”гы нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә, «Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» гы Чистай муниципаль районы Советының 2018 елның 2 февралендәге 30/3 номерлы карары редакциясендәге нигезләмәне, 4.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«4.4. Чистай муниципаль районының муниципаль берәмлеге милке реестры Россия Федерациясе Хөкүмәтенең вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртип белән гамәлгә ашырыла».

2. Чистай муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, Чистай муниципаль районы рәсми сайтында: http://chistopol.tatar.ru/, Татарстан Республикасының рәсми хокукый-мәгълүмат интернет-порталында: pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Чистай муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль районы Башлыгы Д.А.Иванов